**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Президентының «Инженерлык фәннәре өлкәсендә зур өлеш керткән өчен А.Н. Туполев исемендәге Халыкара премияне гамәлгә кую турында» Указына үзгәрешләр кертү хакында**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Инженерлык фәннәре өлкәсендә зур өлеш керткән өчен А.Н. Туполев исемендәге Халыкара премияне гамәлгә кую турында» 2014 елның 1 ноябрендәге ПУ-1014 номерлы Указына (Татарстан Республикасы Президентының 2016 елның 22 февралендәге ПУ-200 номерлы, 2017 елның 9 июнендәге ПУ-488 номерлы, 2018 елның 13 апрелендәге ПУ-309 номерлы, 2021 елның 14 июлендәге ПУ-579 номерлы, 2021 елның 24 декабрендәге ПУ-991 номерлы указлары, Татарстан Республикасы Рәисенең 2023 елның 11 июлендәге 484 номерлы һәм 2025 елның 28 маендагы 420 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Инженерлык фәннәре өлкәсендә күренекле өлеш керткән өчен А.Н. Туполев исемендәге халыкара премия турындагы нигезләмәнең 7 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Комитет утырышлары шәхсән катнашу формасында, шул исәптән видео-конференц-элемтәдән файдалану ярдәмендә дә, кирәк булган саен уздырыла һәм анда Комитет әгъзаларының гомуми саныннан яртысыннан күбрәге катнашкан очракта, гамәлгә хокуклы дип санала.

Комитетның Халыкара премия бирү турында Татарстан Республикасы Рәисенә тәкъдим кертү хакындагы карарлары яшерен тавыш биргән Комитет әгъзаларының күпчелек тавышы белән кабул ителә.»;

б) Инженерлык фәннәре өлкәсендә күренекле өлеш керткән өчен А.Н. Туполев исемендәге халыкара премияне бирү комитеты (алга таба – Комитет) составында:

Комитет составыннан А.П. Бобрышевны, А.М. Пахомовны чыгарырга;

Комитет составына кертергә:

Абросимов Юрий Георгиевичны – «Туполев» акционер җәмгыяте идарәче директоры вазыйфаларын вакытлыча башкаручыны (килешү буенча);

Лаврентьев Александр Петровичны – Татарстан Республикасы Предприятиеләр һәм сәнәгатьчеләр ассоциациясе (эш бирүчеләрнең төбәк берләшмәсе) президентын (килешү буенча);

Охоткин Кирилл Германовичны – «А.Н. Туполев исемендәге Казан илкүләм тикшеренү техник университеты-КАИ» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесе ректорын (килешү буенча);

Комитет әгъзалары вазыйфалары атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Ю.Ф. Гортышовның – «А.Н. Туполев исемендәге Казан илкүләм тикшеренү техник университеты-КАИ» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесенең җылылык техникасы һәм энергетика машиналары төзү кафедрасы профессоры, Комитет секретаре (килешү буенча)»;

Н.Н. Долженковның – «Урал граждан авиациясе заводы» акционер җәмгыяте генераль директоры урынбасары – җәмгыятьнең генераль конструкторы – пилотсыз авиация дивизионы директоры (килешү буенча)».

2. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ
АДМИНИСТРАЦИЯ РАИСА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Казан, Кремль
2026 ел, 20 март
№ 215